ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау федераль хезмәте Идел буе федераль округы буенча департаментының Татарстан Республикасындагы эшчәнлеге турында мәгълүмат һәм Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсенең Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитнең торышы һәм пычрануы, Татарстан Республикасының хакимияте органнарын, идарә органнарын һәм халкын мәгълүмат белән тәэмин итү хакында мәгълүмат турында

Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау федераль хезмәте Идел буе федераль округы буенча департаменты башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Е. Носкованың Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау федераль хезмәте Идел буе федераль округы буенча департаментының Татарстан Республикасындагы эшчәнлеге турындагы, «Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы С.Д. Захаровның Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитнең торышы һәм пычрануы, Татарстан Республикасының хакимияте органнарын, идарә органнарын һәм халкын мәгълүмат белән тәэмин итү хакындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау федераль хезмәте Идел буе федераль округы буенча департаментының Татарстан Республикасындагы эшчәнлеге турында мәгълүматны һәм Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсенең Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитнең торышы һәм пычрануы, Татарстан Республикасының хакимияте органнарын,

идарә органнарын һәм халкын мәгълүмат белән тәэмин итү хакында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе вәкаләтләренең кабатлануын бетерү мәсьәләсен карауны тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Татарстан Республикасында уңайсыз метеорологик шартлар чорында атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруны җайга салу эшләрен оештыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 22 маендагы 407 номерлы карарына аның федераль законнар таләпләренә туры килүенә мониторинг уздыруны һәм аның үтәлешен тикшереп торуны көчәйтүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 8 июле
№ 1047-VI ДС